
Мордовия хатын-кызларынын «Чулпан» жәмгыяви оешмасы житәкчесе Надия Низаметдин кызы Азисова барча хатын-кызларны Яз һәм 8 Март бәйрәме белән ихлас кvнелдән котлый!
Кояш нурларына, тамчылар чынына торенеп март ае да килеп житте. Табигатьнен язгы vзгәреш кичергән бер мәлендә без гvзәл затларыбызнын ин кvркәм бәйрәмен – 8 Март Халыкара хатын-кызлар конен билгеләп vтәбез.       Язгы кояш нурына кvмелгән әлеге бәйрәмдә мәхәббәт, матурлык, ана назы, ягымлылык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, сабырлык, хатын-кызга ихтирам кебек мәнгелек кыйммәтләр чагылыш таба. Бvген хатын-кызларнын кvпчелеге эш белән мәшгуль. Ул бала да тудыра, йорт-жирен дә карый, аны якты һәм жылы итә, остәвенә, карьера ясый, шушы мен торле мәшәкатьләргә чумып калмыйча, vзенен нәзакәтлелеген дә саклый белә. Боларны бары хатын-кыз гына булдыра ала.
Газиз әбекайлар, гаилә учагын сvндерми саклаучы, батырлар vстерvче аналар, сойкемле апа-сенелләр!
Сезнен тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызнын кvнел жылысы һәм игътибары белән тулып, йозләрегез елмаюдан яктырып, нур чәчеп торсын. Йортларыгызда иминлек булсын, тормышыгызга бәрәкәтлелек, сою-сәгадәт, унышлар алып килсен. Кvк йозе аяз, ә бәйрәмнәребез котлы булсын, хормәтле  хатын-кызлар!